ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.07.2020 ел Баулы шәһәре №142

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 8 маендагы 102 номерлы карары белән расланган «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон (02.08.2019 елгы ред.), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2021 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы (30.12.2019 елгы ред.) 159 номерлы карары нигезендә, физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, Баулы муниципаль районы территориясендә физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 8 маендагы 102 номерлы карары белән расланган «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасы чаралары исемлеге» VI бүлегендә:

«2020-2024 елларга спорт резервын әзерләү һәм югары казанышлар спортын үстерү» ярдәмче программасы чаралары исемлеге» III бүлекчәсен әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2.Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасында ел саен Баулы муниципаль районы бюджетын чираттагы финанс елына формалаштырганда Программа чараларын гамәлгә ашыруга акчалар бирүне күздә тота.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның
«____» __________ ____ номерлы
карарына
кушымта

«III. «2020-2024 елларга спорт резервын әзерләү һәм югары
казанышлар спортын үстерү» ярдәмче программасы чаралары исемлеге»

| № п/п | Чара атамасы | Җаваплы башкаручылар | Башкару срогы | Финанслау чыганагы, күләме | Шул исәптән еллар буенча (мең сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1. | Спорт мәктәпләрен махсус җиһазлар, спорт инвентарьлары һәм экипировка белән тәэмин итү | «1нче СП» МБУ «2нче СП» МАУ «3нче КСМ» МАУ | 2020-2024 еллар | республика бюджеты | 335,40 | - | - | - | - |
| 2. | Хоккей буенча Татарстан Республикасы һәм Россия беренчелегендә (А төркеме) катнашу | «3нче КСМ» МАУ | 2020-2024 еллар | республика бюджеты | 272,40 | - | - | - | - |
| 3. | Баулы муниципаль районы территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү, рәсми физкультура - савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру өчен шартлар тәэмин итү | «1нче СП» МБУ каршындагы модульле чаңгы базасы | 2020-2024 еллар | республика бюджеты | 697,79 | - | - | - | - |
| Барлыгы: | | | | | 1305,5 | - | - | - | -» |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 9 | | | | |

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының эшләр
белән идарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов